СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18. 02. 2019 с. Сарманово № 165

Сарман муниципаль районы Советы карарының үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасының 2017 елның 19 июлендәге 56-ЗРТ номерлы “Муниципаль вазифа яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазифасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазифалар яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазифаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында” законын кабул итү сәбәпле һәм Сарман муниципаль районы Советының 2015 елның 18 ноябрендәге 17нче номерлы “Татарстан Республикасының “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставын яңа редакциядә кабул итү турында” карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасының “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Сарман муниципаль районы Советының 2014 елның 17 ноябрендәге 166нчы номерлы “Муниципаль хезмәт вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасының “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафынан хезмәт тәртибе таләпләрен үтәүләрен тикшерү хакында нигезләмәне раслау турында” һәм 2014 елның 17 ноябрендәге 165нче номерлы “Татарстан Республикасының “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәр, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыруы турында һәм шулай ук Татарстан Республикасының “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтләрне биләүче затларның керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыруы турында” карарларын үз көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы рәисе Ф.М. Хөснуллин